РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЙДАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Ленина ул., д. 39, д.Айдарово, 422095
тел. (факс): (84360) 5-34-46,
E-mail: Aydar.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЙДАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин ур., 39 нчы йорт, Айдар авылы, 422095
тел. (факс): (84360) 5-34-46,
E-mail: Aydar.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318091 ОГРН 1061675010825 ИНН/КПП 1619004436/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 10» октябрь 2025 г. № 26

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башкарма комитетының 2023 елның 22 март № 11 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә кулланылган терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2025 елның 12 сентябрендәге 09/13-09/4246 номерлы хатын карап, 1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 89-ФЗ номерлы, 2002 елның 10 гыйнварындагы «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 7-ФЗ номерлы, 2009 елның 23 ноябрендәге «Энергияне сак тоту турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 261-ФЗ номерлы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы «Җитештерү һәм куллану калдыкларын тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башкарма комитетының 2023 елның 22 март № 11 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә кулланылган терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» карарына үзгәреш кертергә, 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп:«4. Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урынының (урыннарының) урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә.

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге башкарма комитетының 2023 елның 22 март №11 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә кулланылган терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» карарының 4.1. пункты үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга: http://tulachi.tatarstan.ru.

Айдар авыл җирлеге башлыгы Х.Ш.Хәсәншин